«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Варварино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы
КАРАРЫ

2022 елның 18 марты №30

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Варварино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 14 ноябрендәге 54 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге үзгәрешләргә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Варварино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 3 статьяның 1 пунктындагы 4 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә

“- җирле үзидарә органнары, бюджет, казна учреждениеләре үзләренә караган җир кишәрлекләренә карата дини һәм хәйрия әһәмиятендәге биналар, төзелмәләр һәм корылмалар урнашкан җир кишәрлекләренә, шулай ук күрсәтелгән объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата;”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Варварино
авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
башлыгы- Совет рәисе Р.Т.Нотфуллин